КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 05 май г.Казань № 570

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 8 май, 307 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 8 май, 307 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 8 октябрь, 744 нче; 2015 ел, 25 февраль, 113 нче; 2015 ел, 25 апрель, 286 нчы; 2016 ел, 8 февраль, 78 нче; 2016 ел, 6 август, 532 нче; 2017 ел, 13 гыйнвар, 5 нче; 2017 ел, 10 июль, 469 нчы; 2017 ел, 24 ноябрь, 901 нче; 2018 ел, 23 апрель, 279 нчы; 2018 ел, 25 июнь, 511 нче; 2018 ел, 15 декабрь, 1141 нче, 2019 ел, 2 сентябрь, 766 нчы, 2020 ел, 23 сентябрь, 861 нче, 2020 ел. 14 декабрь, 1131 нче, 2021 ел, 28 июнь, 508 нче, 2022 ел, 14 октябрь, 1101 нче, 2022 ел, 27 декабрь, 1422 нче, 2023 ел, 1 февраль, 80 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәдә:

1.4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

3.1 пунктта:

3.1.5 пунктчада «сатып алу турында документлар» сүзләрен «сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрләр» сүзләренә алмаштырырга, «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

3.1.6 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

5.1 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары, Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләре ихтыяҗлары өчен кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) үзәкләштереп билгеләүне һәм алар өчен Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты кайтартучыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү функцияләрен гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы заказчылары ихтыяҗлары өчен (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләүне оештыру тәртибендә:

1.3 пунктта «электрон формада чикләнгән катнашу белән конкурс,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.1 пунктта:

унөченче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

ундүртенче абзацта «сатып алу документлары» сүзләрен «сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәләр» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктта:

4.1.2 пунктчаның дүртенче абзацына түбәндәге сүзләр өстәргә: Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «, Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр каталогын сатып алу өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында булдыру һәм алып бару кагыйдәләрен һәм Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр каталогыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 8 февралендәге 145 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр каталогыннан файдалану кагыйдәләренең 5 пункты нигезендә өстәмә мәгълүмат, өстәмә куллану үзлекләре, шул исәптән товарның, эшнең, хезмәт күрсәтүнең функциональ, техник, сыйфатлы, эксплуатацияләү характеристикалары күрсәтелгән очракта» сүзләрен өстәргә;

4.1.4 пунктчада:

беренче абзацта «сатып алу турында хәбәрнамәләр» сүзләрен «сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәләр» сүзләренә алмаштырырга, «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «сатып алу турында хәбәрнамә һәм (яисә) сатып алу турында документация» сүзләрен «сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамә, техник бирем, контракт проекты» сүзләренә алмаштырырга;

4.1.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.5. Сатып алу турында хәбәрнамәне, техник биремне, контракт проектын үзгәртү кирәк булган очракта яисә тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүне үткәрүдән баш тарткан очракта вәкаләтле органга тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүне уздырудан баш тарту йә сатып алуларны гамәлгә ашыру турында хәбәргә, техник биремгә, контракт проектына үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү өчен законнарда билгеләнгән срок тәмамланырга ике көн кала хәбәр итәләр.»;

4.2 пунктта:

4.2.5 пунктчада «документларын» сүзен «сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәне» сүзләренә алмаштырырга;

4.2.6 пунктча үз көчен югалткан дип танырга;

4.2.7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.7. Әлеге Тәртипнең 4.2.5 пунктчасы нигезендә аны әзерләгән көннән алып бер эш көне эчендә сатып алу турында хәбәрне бердәм мәгълүмат системасында урнаштыра.

Кирәк булганда сатып алу турында хәбәрнамәгә, техник биремгә, контракт проектына үзгәрешләр кертә.»;

4.2.8 пунктчада «сатып алу турында документлар» сүзләрен «сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәләр» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктның икенче абзацында (килешү)» сүзен төшереп калдырырга;

5.1 пунктта:

5.1.1 пунктчаның беренче абзацында «дәүләт контракты (граждан-хокукый шартнамәсе) проекты» сүзләрен «контракт проекты» сүзләренә алмаштырырга;

5.1.2 пунктчаның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «, Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр каталогын сатып алу өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында булдыру һәм алып бару кагыйдәләрен һәм Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр каталогыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 8 февралендәге 145 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр каталогыннан файдалану кагыйдәләренең 5 пункты нигезендә өстәмә мәгълүмат, өстәмә куллану үзлекләре, шул исәптән товарның, эшнең, хезмәт күрсәтүнең функциональ, техник, сыйфатлы, эксплуатацияләү характеристикалары күрсәтелгән очракта сатып алуга заявкаларда расланган техник биремне, контрактның расланган проектын, сатып алуны расланган нигезләүне (булган очракта), контрактның расланган башлангыч (максималь) бәясен, эквивалентлыкның расланган анализын (товарны сатып алганда) үз эченә алырга тиеш.»;

5.1.4 пунктчада:

беренче абзацта «сатып алу турында хәбәрнамәләр» сүзләрен «сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәләр» сүзләренә алмаштырырга, «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «сатып алу турында хәбәрнамә һәм (яисә) сатып алу турында документация» сүзләрен «сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамә, техник бирем, контракт проекты» сүзләренә алмаштырырга;

5.1.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1.5. Сатып алу турында хәбәрнамәне, техник биремне, контракт проектын үзгәртү кирәк булган очракта яисә тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүне үткәрүдән баш тарткан очракта вәкаләтле органга тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүне уздырудан баш тарту йә сатып алуларны гамәлгә ашыру турында хәбәргә, техник биремгә, контракт проектына үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү өчен законнарда билгеләнгән срок тәмамланырга ике көн кала хәбәр итәләр.»;

5.2 пунктта:

5.2.5 пунктчада «документларын» сүзен «сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәне» сүзләренә алмаштырырга;

5.2.6  пунктча үз көчен югалткан дип таныррга;

5.2.7 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2.7. Әлеге Тәртипнең 5.2.5 пунктчасы нигезендә аны әзерләгән көннән алып бер эш көне эчендә сатып алу турында хәбәрне бердәм мәгълүмат системасында урнаштыра.

Кирәк булганда сатып алу турында хәбәрнамәгә, техник биремгә, контракт проектына үзгәрешләр кертә.»;

5.2.8 пунктчада «сатып алу турында документлар» сүзләрен «сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамәләр» сүзләренә алмаштырырга;

5.3 пунктның икенче абзацында (килешү)» сүзен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин